СОВЕТ ПЕЧИЩИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ПЕЧИЩИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

05.03.2018

КАРАР

№ 31-151

с. Печищи

Салым түләүчеләрнең аерым категорияләренә җир салымы түләү буенча салым ташламалары бирү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Янгыннан ирекле саклау турында» 2011 елның 6 маендагы 100-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау турында» 01.08.2011 № 48-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә таянып,

ТР Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Салым түләүчеләрнең түбәндәге категорияләренә җирнең кадастр бәясеннән 0,2 % күләмендә җир салымының киметелгән ставкасын куллану рәвешендә җир салымын түләү буенча салым ташламасын түбәндәгечә күрергә:

- янгыннан ирекле саклау буенча иҗтимагый берләшмәләргә.
- янгыннан ирекле саклау хезмәткәрләренә һәм ирекле янгын сүндерүчеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән салым түләүчеләр өчен ташламалар эшкуарлык эшчәнлеге өчен файдаланылмый торган, ә берничә җир кишәрлеге (өлешләре) булган җир кишәрлекләренә карата бары тик бер җир кишәрлеге өчен генә бирелә дип билгеләргә".

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән салым түләүче-физик затлар салым органына салым ташламалары бирү турында гариза үз сайлаулары буенча тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган документларны тапшырырга хокуклы".

4. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Совет Рәисе урынбасары,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Печищи авыл җирлеге башлыгы урынбасары Т.С. Нуруллин